**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БИРЮЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422737, Республика Татарстан, Высокогорский район, п.Бирюлинского з/с, ул. Кольцевая, 33

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ БӨРЕЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422737 Татарстан Республикасы, Биектау районы, Бөреле җәнлек совхозы пос, Божра ур., 33

Тел./факс: +7(84365) 76-5-45, e-mail: Brl.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**16 апреля 2021ел.** **№ 16**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы «Җирләү һәм күмү эше турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елдагы 28 гыйнварындагы 73 номерлы «2021 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы «Татарстан Республикасында «Җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6424,98 сум күләмендә 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә һәм 2021 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Бөреле авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Т.Х.Багаутдинов

1 нче кушымта

РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 15 апреля № 16 карары белән

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе**

| **Хезмәтләр исеме** | **Хезмәтләрнең бәясе *(сум)*** |
|---|---|
| 1. Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | бушлай |
| 2. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3746,52 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 852,24 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1826,22 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |

2 нче кушымта
РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Бөреле авыл
җирлеге Башкарма комитетының 2021
елның 15 апреля № 16 карары белән

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе**

| **Хезмәтләр исеме** | **Хезмәтләрнең бәясе *(сум)*** |
|---|---|
| 1. Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | бушлай |
| 2. Кәфенләү | 487,00 |
| 3. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3259,53 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 852,24 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1826,21 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |